мәдәният йорты» МБУнең хокуклары һәм бурычлары варисы итеп ТР ЧМР ҮКС МБУ билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының «Иске Кади авыл мәдәният йорты» МБУны тоташтыру рәвешендә ТР ЧМР ҮКС МБУ үзгәртеп кору буенча оештыру чаралары планын (1 нче кушымта) расларга.

4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының «Иске Кади авыл мәдәният йорты» МБУны тоташтыру рәвешендә ТР ЧМР ҮКС МБУ үзгәртеп кору комиссиясен төзергә, аның составын расларга (2 нче кушымта).

5. Реорганизацияләүгә вәкаләтле комиссиягә:

5.1. Кушылу нәтиҗәсендә эшчәнлеген туктатучы учреждениеләр балансында булган матди байлыкларны һәм финанс йөкләмәләрне инвентаризацияләүне оештырырга һәм үткәрергә.

5.2. Билгеләнгән тәртиптә тапшыру актын әзерләргә.

5.3. ТР ЧМР ҮКС МБУнең яңа структурасын һәм штат расписаниесен формалаштырырга һәм расларга.

5.4. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының «Иске Кади мәдәният йорты» МБУ директорын Федераль салым хезмәтенә үзгәртеп кору процедурасы башлану турында хәбәрнамә бирү өчен җаваплы иттереп билгеләргә.

5.5. Таныш кредиторларга үзгәртеп кору процедурасы башлану турындагы хәбәрне җибәргәннән соң биш эш көне эчендә үзгәртеп кору башлануы турында язма формада хәбәр итәргә.

5.6. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының «Иске Кади авыл мәдәният йорты» МБУ директорына Юридик затларның бердәм дәүләт реестрына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге Башкарма комитетының «Иске Кади авылы мәдәният йорты» МБУне ТР ЧМР ҮКС МБУга тоташтыру рәвешендә үзгәртеп кору процедурасын башлау турында язманы керткәннән соң биш эш көне дәвамында, ике тапкыр, айга бер тапкыр ешлык белән «Вестник государственной регистрации» журналында һәм «Федресурс» интернет басмасында да үзгәртеп кору турында хәбәрнамә урнаштырырга.

6. Чирмешән муниципаль районының Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә «Иске Кади авылы мәдәният йорты» МБУ хезмәткәрләренә үзгәртеп кору тәмамланырга ике айдан да соңга калмыйча хезмәт килешүе шартларын сизелерлек үзгәртү турында хәбәр итү турында күрсәтмә чыгарырга.

7. ТР ЧМР ҮКС МБУ директоры М.А.Рыбкинага Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәве үткәрергә.

8. ТР ЧМР ҮКС МБУ юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язылу вакытыннан алып үзгәртеп корылган дип санарга.

1 нче кушымта
2022 елның 25 ноябрендәге 22 номерлы
карарына

Кушу формасында «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУ булдыру буенча оештыру чаралары планы

| п\п | Чаралар атамасы | Үтәү вакыты | Башкаручы |
|---|---|---|---|
| 1. | Үзгәртеп кору процедурасы башлану турында Федераль салым хезмәтенә хәбәр итү «Үзгәртеп кору процедурасы башлану турында хәбәр» | Үзгәртеп кору турында карар кабул ителгәннән соң 3 эш көне эчендә | Иске Кади мәдәният йорты МБУ |
| 2. | «Вестник государственной регистрации» журналында үзгәртеп кору турында хәбәрнамә урнаштыру | Ике тапкыр, айга бер тапкыр ешлык белән (беренче тапкыр - үзгәртеп кору язмасын ясаганнан соң, икенче тапкыр беренче басмадан соң бер айдан) | Иске Кади мәдәният йорты МБУ |
| 3. | Кредиторларга язма рәвештә хәбәр итү | Ай дәвамында | Иске Кади мәдәният йорты МБУ |
| 4. | Хезмәткәрләргә үзгәртеп кору (хезмәт килешүләренең мөһим шартларын үзгәртү) турында язма формада хәбәр итү | Биш эш көне эчендә, төзү турындагы карарны имзалаганнан соң | Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитеты |
| 5. | Районның 18 муниципаль учреждениесе мөлкәтенә һәм финанс йөкләмәләренә инвентаризация үткәрү, тапшыру актын төзү, имзалау | 2022 елның 1 декабренә кадәр | Үзгәртеп кору комиссиясе |
| 6. | Тапшыру актын раслау | 2022 елның 1 декабренә кадәр | Үзгәртеп кору комиссиясе |
| 7. | Юридик затларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органга тоташтырылган юридик затларның эшчәнлеген туктату турында Юридик затларның | 2022 елның декабре | ТР ЧМР «ҮКС» МБУ |

2 нче кушымта
2022 елның 25 ноябрендәге 22 номерлы
карарына

«Иске Кади авыл мәдәният йорты» МБУны «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУга кушып үзгәртеп кору комиссиясе
СОСТАВЫ

| п\п | ФИАт.ис. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Мөктәсимов Нәкыйп Вәлиҗан улы | Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| 2. | Загртдинова Рәмзия Рәфыйк кызы | Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитетының баш хисапчысы, рәис урынбасары |
| 3. | Илалиева Минзилә Ләбиб кызы | «Әккәрәй авыл мәдәният йорты» МБУ директоры |
| 4. | Нотфуллина Ләйсән Габделхай кызы<br>Бикулов Рәфыйк Валимөхәмәт улы | Якты Тау авыл клубы мөдире<br><br>Светлогорский авыл клубы мөдире (ведомство карамагындагы клублар мөдирләрен барысын да кертәбез ) |
| 5. | Мөктәсимова Рузилә Вәлиҗан кызы | Иске Кади авылы мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе |
| 6. | Рыбкина М.А. | «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУ директоры |